# « «TATARTIME» – татар телен саклау һәм үстерү» темасына проект

Башкарды: 10нчы сыйныф укучысы
Әхмадуллина Камилә Айдар кызы
Җитәкче: татар теле һәм әдәбияты
укытучысы Асадуллина Энҗе Васил кызы

# Проблематика

Бүгенге мәгълүмати технологияләр үсеше чорында телләрнең сакланышы һәм кулланылышы турыдан-туры цифрлы мохиткә бәйле. Глобальләшү, Интернет киңлегендә рус һәм инглиз телләренең өстенлек итүе нәтиҗәсендә, татар теле яшьләр арасында көндәлек аралашу теле буларак кулланылышын югалта бара. Шулай ук, татар теле «мәктәп фәне» генә булып кала. Яшь нәселне татар телен өйрәнүдә кызыксындыру өчен платформалар юк.





## Актуальлек

Шул ук вакытта яшьләрнең күпчелек вакыты смартфоннарда, социаль челтәрләрдә һәм мобиль кушымталарда үтә. Әгәр татар теле әлеге мохиттә заманча форматта тәкъдим ителсә, ул яңадан популяр һәм ихтыяҗлы телгә әйләнә ала.

## Бурычлар

Шуңа күрә татар телен саклау, үстерү һәм популярлаштыру өчен цифрлы технологияләргә нигезләнгән республикакүләм платформа булдыру – бүгенге көндә аеруча актуаль бурыч.

# Проектнын максатчан аудиториясы

1) 5-11 сыйныф укучылары
2) Студентлар
3) Татар телен өйрәнергә теләүчеләр



## «TATARTIME» мобиль кушымтасы

Яшьләрнең татар теленә карата кызыксыну барлыкка килсен өчен, мин мобиль кушымтасы уйлап чыгарырга булдым. Минем уйлавымча, бу иң мантыйклы фикернең берсе, чөнки барлык яшьләр буш вакытын телефонда үткәрәләр.

- 5 минутлык видеодәресләр
- Уеннар, тестлар
- Татарча AI-ассистент
- Челенджлар
- Баллар һәм рейтинг

## Көтелгән нәтиҗәләр:

- Татар теленә кызыксынуның артуы;
- Татар телен көндәлек аралашуда кулланучылар саны үсүе;
- Яшьләр арасында татар теленең абруе күтәрелү;
- Мәгариф процессында татар телен өйрәнүнең нәтиҗәлелегә артуы;
- Татар телен саклау һәм үстерү буенча цифрлы мохит булдыру.



## 3.Йомгаклау

«TATARTIME» – татар телен саклау һәм үстерү өчен заманча, инновацион һәм республика күләмендә гамәлгә ашырыла ала торган проект. Ул татар телен яшьләр тормышының аерылгысыз өлешенә әйләндерүне максат итеп куя.

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!